**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**422610 г.Лаишево,**
**ул. Первомайская, д.39**
**тел: (8-84378) 2-51-51**
**факс: (8-84378) 2-55-55**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ район СОВЕТЫ**

**422610 Лаеш ш.,**
**Беренче май урамы, 39 нчы йорт,**
**тел: (8-84378) 2-51-51**
**факс: (8-84378) 2-55-55**

---

**2023 елның 23 октябре** **109-РС номер**

## КАРАР

### «Лаеш муниципаль районы территориясендә көнкүреш һәм сәнәгать калдыкларын утильләштерүне һәм эшкәртүне оештыру турында» 2012 елның 10 декабрендәге 76-РС номерлы Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Җир асты байлыклары турында» Россия Федерациясе Законына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2022елның 14 июлендәге 343-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Лаеш муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Лаеш муниципаль районы территориясендә көнкүреш һәм сәнәгать калдыкларын утильләштерүне һәм эшкәртүне оештыру турында» 2012 елның 10 декабрендәге 76-РС номерлы Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы карарына(кушымта нигезендә) үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.

2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Советының төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык мәсьәләләре буенча комиссиягә йөкләргә.

**Башлык – муниципаль район**
**Советы Рәисе** **И.Ф. Зарипов**

*Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2023 елның «23» октябрендәге 109-РС номерлы карарына кушымта*

«Лаеш муниципаль районы территориясендә көнкүреш һәм сәнәгать калдыкларын утильләштерүне һәм эшкәртүне оештыру турында» 2012 елның 10 декабрендәге 76-РС номерлы Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү

**1) I бүлекнең 6 пунктындагы 9 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

- калдыкларны урнаштыру объектлары - калдыкларны, шул исәптән җир асты байлыкларыннан файдалану калдыкларын(Россия Федерациясенең 1992 елның 21 февралендәге 2395-I номерлы "Җир асты байлыклары турында" гы Законына ярашлы кулланылырга тиешле Тау токымнарын саклау объектларыннан тыш) урнаштыру өчен билгеләнгән махсус җиһазландырылган корылмалар һәм калдыкларны саклау объектларын һәм калдыкларны күмү объектларын үз эченә алган корылмалар.